РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422071, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Кильдебяк, ул. Чулпаново, 20а
тел. (84362) 45-5-50

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДЕБӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422071, Татарстан Республикасы, Саба районы, Килдебәк авылы, Чулпан урамы, 20а йорт
тел. (84362) 45-5-50

e-mail: Kilb.sab@tatar.ru

2018 елның 03 августы

№17

РЕШЕНИЕ

КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Килдебәк авыл җирлеге Советы тарафыннан
2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән
31 нче номерлы «Татарстан Республикасы
Саба районы Килдебәк авыл җирлегендә физик
затларның мөлкәт салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 32 нче бүлеге,Россия Федерациясе Бюджет кодексының 64 нче маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Саба районы Килдебәк авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 31 нче номерлы Килдебәк авыл җирлеге Советы карары белән расланган “Килдебәк авыл җирлегендә физик затларның мөлкәт салымы турында” карарына (Килдебәк авыл җирлеге Советының 2015 елның 06 нче августында кабул ителгән №27, 2015 елның 7 октябрендә кабул ителгән №8 карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2 нче пункты 2 нче пунктчасы 2 нче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:
“торак йортларны, торак йортларның өлешләрен”

1.2. карарның 2 нче пункты 3 нче пунктчасы 2 нче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:
“фатирларны, фатирларның өлешләрен”.

2. Әлеге карарның гамәлен 2015 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ruадресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча һәм авыл җирлегенең информацион стендларында бастырырга.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Загидуллин